РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар
31 гыйнвар 2022 ел | № 4

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты
к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2021 ел, № 2 карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче /Б.Ф.Хәсәнов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге
Башкарма комитетының
30.01.2022 ел, 4 нче санлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегендә җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле
үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3203,78 |
| Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 834,79 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2926,11 |
| **Барлыгы** | 6964,68 |

Җитәкче /Б.Ф.Хәсәнов/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге
Башкарма комитетының
30.01.2022 ел, 2 нче санлы
карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегендә күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,00 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 993,95 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер тактадары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2300,80 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 851,70 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2818,23 |
| **Барлыгы** | 6964,68 |

Җитәкче /Б.Ф.Хәсәнов/